МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.05.2018 г.Казань № 340

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 18 июнендә 4746 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2017 елның 11 июлендәге 459 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында һәм Социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларда хезмәтләр күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя уздыру буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 23.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2017 елның 11 июлендәге 459 номерлы боерыгы (2017 елның 19 декабрендәге 882 номерлы боерык нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта дүртенче абзацны, 2.2 пунктта алтынчы абзацны һәм 2.4 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Иҗтимагый совет составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланучы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршында иҗтимагый совет төзү тәртибе нигезендә 13 кешелек составта төзелә.».

2. Кушымтада бирелгән Социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларда хезмәтләр күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя уздыру буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмәне расларга.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.Ф.Вәлиулловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 03.05.2018 № 340 боерыгы белән расланды

Социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларда хезмәтләр күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя уздыру буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларда хезмәтләр күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя уздыру буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет (алга таба – Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) каршындагы киңәшмә орган булып тора, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның хезмәтләр күрсәтү шартларының сыйфаты һәм алар эшчәнлегенең сыйфатын арттыру турында мәгълүматтан гражданнарның файдалану хокукын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

1.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен һәм аларның эшчәнлеген яхшырту буенча тәкъдимнәрне үз эченә алган карары алар керү датасыннан соң бер ай эчендә Министрлык тарафыннан зарури каралырга һәм социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча аның тарафыннан чаралар эшләнгәндә һәм аларның җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләгәндә исәпкә алынырга тиеш.

1.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

1.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның эше ирекле нигездә, ачык булу һәм партнерлык принципларында һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына катгый рәвештә туры китереп корыла.

1.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет үз эшен гражданнарның иҗтимагый институтлары вәкилләренең, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының уртак мәнфәгатьләре нигезендә башкара.

1.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлык тарафыннан үзенең рәсми сайтындагы «Хезмәтләр күрсәтү шартларына бәйсез бәя» бүлегендә урнаштырылырга тиеш.

## 2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның эшчәнлегендә төп максатлар булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм гамәлгә куючысы булып Татарстан Республикасы торган социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре хисабыннан социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләтнеке булмаган социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар (алга таба – социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар) тарафыннан хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатына иҗтимагый контрольне көчәйтү;

социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә ачык һәм законлы булу принципларын үстерү.

2.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатына бәйсез бәяләү уздыру;

социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул ителгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтелү шартларының сыйфаты турында җәмәгатьчелекнең хәбәрдар булу дәрәҗәсен арттыру.

2.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары, аның эш нәтиҗәләренә карап, шулай ук Россия Федерациясендәге икътисадый, социаль һәм сәяси вәзгыятьне исәпкә алып үзгәртелергә һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

2.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет үзенә йөкләнгән бурычлар кысаларында:

үзләренә карата бәйсез бәяләү уздырыла торган социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның исемлеген билгели;

эшләр, хезмәтләр сатып алу турында проектларны, шулай ук Министрлык белән социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтелү шартларының сыйфаты турында мәгълүматлар җыюны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыручы оешма (алга таба – оператор) белән ике арада төзелә торган дәүләт контрактлары проектларын карауда катнаша;

оператор тапшырган мәгълүматны исәпкә алып, социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтелүнең сыйфатын бәйсез бәяләүне гамәлгә ашыра;

социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтелү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен, шулай ук алар эшчәнлегенең сыйфатын арттыру турында тәкъдимнәрне Министрлыкка тапшыра.

## 3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның составы

3.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан формалаштырыла.

3.2. Министрлык, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составы расланган көннән соң 30 көн узганчы, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның беренче утырышын уздыруны оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның рәисе һәм рәисе урынбасары сайлана. Карар Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан ачык тавыш бирү юлы белән алынган тавышларның күпчелеге нигезендә кабул ителә.

3.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисен яисә рәисе урынбасарын вазыйфасыннан азат итү турында мәсьәлә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый советы рәисенең, Министрлык җитәкчесенең мөрәҗәгате буенча, шулай ук Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенең яисә рәисе урынбасарының шәхси гаризасы буенча яисә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми исәбендә кимендә биштән бер өлешен тәшкил иткән күләмдә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары төркеменең тәкъдиме буенча карала. Карар Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми исәбендә алынган тавышларның күпчелеге нигезендә кабул ителә.

3.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның җаваплы сәркатибен билгели.

3.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составы өч еллык срокка раслана. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советны яңа срокка формалаштырганда аның составының кимендә өчтән бер өлешен үзгәртү гамәлгә ашырыла.

3.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составына түбәндәгеләрнең вәкилләре керә алмый:

дәүләт хакимияте органнарының;

социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек башкаручы иҗтимагый берләшмәләрнең;

социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек башкаручы оешмаларның җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре.

3.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет мондый бәянең нәтиҗәләре хакында сөйләшү һәм аны формалаштыру өчен үз эшенә социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек башкаручы иҗтимагый берләшмәләрнең һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләрен җәлеп итә.

3.8. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының саны биш кешедән кимрәк була алмый.

3.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенең карары нигезендә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе буенча туктатыла, түбәндәге очракларда:

аңа Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаеп тагылганда;

аңа карата административ арест рәвешендә административ җәза билгеләнгәндә;

аны дәүләт хакимияте органының закон чыгару (сайлаулы) депутатына кандидат, җирле үзидарә органында сайлаулы вазыйфага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яки вәкаләтле вәкиле вазыйфасына кандидат буларак теркәгәндә, шулай ук ул Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициатив төркем составына кертелгән очракта.

3.10. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның вәкаләтләр чоры беткәндә;

ул Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза тапшырганда;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшендә аның сәламәтлеге торышы буенча катнашуга сәләтле булмавы очрагында;

аңа карата чыгарылган гаепләү турында суд карары законлы көченә кергәндә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә ул эшкә сәләтсез яки сәбәпсез юк булучы дип танылганда;

аның тарафыннан этик нормалар тупас бозылганда – Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышында катнашкан Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән карар нигезендә;

системалы рәвештә (өчтән артык мәртәбә) хөрмәткә лаек сәбәпсез Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышлары эшендә катнашмаганда – Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителгән Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары буенча;

системалы рәвештә (ике мәртәбәдән артык) хөрмәткә лаек сәбәпләрсез Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенең яисә рәисе урынбасарының йөкләмәләрен үтәмәгәндә – Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителгән Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары буенча;

ул Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә;

чит ил дәүләте гражданлыгын алгач (билгеле бер дәүләт гражданлыгын алгач);

Россия Федерациясе гражданлыгы беткәч.

3.11. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктату Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы яисә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенең яисә рәисе урынбасарының күрсәтмәсе нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.10 пунктында каралган шартлар ачыкланган очракта Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасы:

дәүләт серен, шәхси белешмәләр турында мәгълүматларны һәм аннан файдалану чикле булган мәгълүматны тәшкил итүче мәгълүматтан файдалануга бәйле рәвештә федераль законнарда аларга үтеп керү чикләнә торган чаралардан кала, социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның эшчәнлеген бәяләүгә кагыла торган һәм Министрлык инициативасы белән үткәрелүче барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, “түгәрәк өстәл”ләрдә һ.б.) катнашырга;

инициатив тәртиптә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советка аналитик язулар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм җибәрергә;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе аша Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын уздыру тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышына көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерүдә катнашу өчен чакырылучы затларның кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советы әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы:

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе биргән йөкләмәләрне үтәргә;

әлеге Нигезләмәдә каралган Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның эш тәртибен белергә һәм үтәргә;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет тарафыннан төзелүче эксперт, эш төркемнәре, комиссияләр, башка эш органнары эшендә катнашырга.

## 5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет үз эшен Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе буенча Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышында раслана торган планнарга һәм программаларга туры китереп оештыра.

5.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшен планлаштыру Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенең һәм Министрлыкның тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер мәртәбәдән дә ким булмаган күләмдә үткәрелә. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышлары, әгәр аларда Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзасы, утырышта шәхсән катнашу мөмкинлеге булмаганда, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын яки үз фикерен язмача, факсимиль яки электрон почта аша, бу хакта Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенә яки Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе урынбасарына, яки Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның җаваплы сәркатибенә алдан хәбәр итеп, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыра ала. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары утыршында катнашучылар исәбенә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның башка әгъзаларына үзләренең тавышларын ышанып тапшырган Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары да өстәлә.

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карарлары тавышларның гади күпчелеге нигезендә кабул ителә.

5.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе, ул булмый торганда – Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе урынбасары уздыра.

5.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе:

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның эш планнарын әзерли, шулай ук үзгәрешләр кертә һәм раслау өчен аларны Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советка кертә;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен раслый;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет киңәшләренә, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет беркетмәләренә һәм башка документларына кул куя;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын уздыру вакытын һәм урынын билгели;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге кысаларында үзенә йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларына үтәү өчен йөкләмәләр бирә;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет исеменнән гарызнамәләргә, киңәшләргә, тәкъдимнәргә, җавапларга, аңлатмаларга һәм мөрәҗәгатьләргә кул куя;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле бүтән функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә булмый торган чорда соңгысының вазыйфаларын башкара;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм раслау өчен аны Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенә тапшыра;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе йөкләмәсе буенча Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле бүтән функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.8. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның җаваплы сәркатибе:

утырышлар өчен материаллар һәм карарларның проектларын әзерләүне оештыра;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышын үткәрүнең урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзаларына хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның һәм Министрлыкның үзара оешкан хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм сыйфатны бәйсез бәяләү буенча кабул ителгән карарларның үтәлешенә контрольлекне гамәлгә ашыра;

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзегәндә катнаша.

5.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенең урынбасары белән килештереп, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларында мәсьәләләрне тыңлауга һәм фикер алышуга әзерләү өчен эш, эксперт төркемнәренә һәм башка төрле эш органнарына берләшергә, материалларны әзерләү өчен Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составына кермәүче белгечләрне җәлеп итәргә мөмкин.

5.10. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары нигезендә, Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларына Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет тарафыннан каралучы мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнарның, коммерциячел булмаган оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар һәм белгечләр чакырылырга мөмкин. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышларында Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет чакыруы буенча катнаша ала.

5.11. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карап тикшерүенә тапшырыла торган материаллар Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисенең урынбасарына аларны карап тикшерү планлаштырылган Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет утырышының билгеләнгән датасына кадәр ун календарь көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Материалларны тагын да соңрак срокларда тапшыру Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары белән килештерелә.

5.12. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Министрлык гамәлгә ашыра.

---